КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 сентябрь г.Казань № 813

Татарстан Республикасының Түбән Кама, Әлмәт һәм Лениногорск муниципаль районнары территорияләрендә төзелә торган «АлмА» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясен планлаштыру проектын раслау турында

Татарстан Республикасының Түбән Кама, Әлмәт һәм Лениногорск муниципаль районнары территорияләрендә төзелә торган «АлмА» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 3.1 өлеше нигезендә шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Түбән Кама, Әлмәт һәм Лениногорск муниципаль районнары территорияләрендә төзелә торган «АлмА» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясен планлаштыру проектын расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 9 сентябрь, 813 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының Түбән Кама, Әлмәт һәм Лениногорск муниципаль районнары территорияләрендә төзелә торган «АлмА» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясен планлаштыру проекты

Татарстан Республикасының Түбән Кама, Әлмәт һәм Лениногорск муниципаль районнары территорияләрендә төзелә торган «АлмА» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясен планлаштыру проекты түбәндәгеләрдән тора:

гомуми нигезләмәләрдән;

территорияне планлаштыру проектын эшләгәндә кулланыла торган закон, норматив хокукый актлар, норматив һәм башка документлардан;

территорияләрне планлаштыру (шул исәптән кызыл линияләр), планлаштыра торган структураның гамәлдәге һәм планга кертелә торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларының планлаштырыла торган урнаштыру зоналары чикләре сызымнарыннан;

территорияне план нигезендә үстерү тасвирнамәләре, шул исәптән территорияләрнең төзелеш тыгызлыгы һәм параметрлары турындагы нигезләмәдән, торак билгеләнешендәге капиталь төзелеш объектлары тасвирнамәләре турындагы нигезләмәдән, иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге капиталь төзелеш объектлары тасвирнамәләре турындагы нигезләмәдән, җитештерү билгеләнешендәге капиталь төзелеш объектлары тасвирнамәләре турындагы нигезләмәдән;

коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары тасвирнамәләре турындагы нигезләмәдән, шул исәптән коммуналь инфраструктура объектлары тасвирнамәләре турындагы нигезләмәдән, транспорт инфраструктурасы объектлары тасвирнамәләре турындагы нигезләмәдән, социаль инфраструктура объектлары тасвирнамәләре турындагы нигезләмәдән;

территорияне план нигезендә үстерү чираты турындагы нигезләмәдән.